КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2021 ел, 6 декабрь г.Казань № 1168

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгы мәсьәләләре» 2005 ел, 6 июль, 317 нче карары белән расланган Татарстан Республикасының Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгы турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы территориясендә юл хәрәкәтен оештыру өлкәсендә республика дәүләт контролен гамәлгә ашыру тәртибен раслау турында» 2019 ел, 30 март, 246 нчы карары үз көчен югалткан дип тану хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгы мәсьәләләре» 2005 ел, 6 июль, 317 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2005 ел, 29 декабрь, 660 нчы; 2006 ел, 19 июнь, 312 нче; 2010 ел, 31 май, 419 нчы; 2010 ел, 17 декабрь, 1078 нче; 2011 ел, 26 октябрь, 890 нчы; 2011 ел, 23 декабрь, 1060 нчы; 2012 ел, 2 июнь, 466 нчы; 2012 ел, 10 октябрь, 846 нчы; 2013 ел, 19 март, 185 нче; 2013 ел, 4 декабрь, 955 нче; 2013 ел, 11 декабрь, 974 нче; 2014 ел, 4 июнь, 376 нчы; 2016 ел, 19 март, 150 нче; 2016 ел, 29 октябрь, 796 нчы; 2017 ел, 3 февраль, 58 нче; 2017 ел, 20 апрель, 232 нче; 2017 ел, 18 декабрь, 1008 нче; 2018 ел, 22 март, 161 нче; 2018 ел, 5 июнь, 430 нчы; 2018 ел, 17 декабрь, 1155 нче; 2019 ел, 16 март, 185 нче; 2019 ел, 22 июль, 613 нче; 2020 ел, 11 февраль, 99 нчы; 2020 ел, 21 апрель, 312 нче;

2020 ел, 11 июль, 575 нче; 2020 ел, 19 август, 710 нчы; 2021 ел, 21 гыйнвар, 19 нчы; 2021 ел, 18 июнь, 476 нчы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Татарстан Республикасының Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгы турындагы нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

3.1 пунктта:

бишенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«җиңел такси белән пассажирлар йөртү һәм багаж ташу өлкәсендә төбәк дәүләт контроле (күзәтчелеге) (03.03.03 *);»;

җиденче һәм сигезенче абзацларны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«автомобиль транспортында, шәһәр җир өсте электр транспортында һәм юл хуҗалыгында төбәк дәүләт контроле (күзәтчелеге) (03.03.05 *);

«Татарстан Республикасы башкарма хакимият органнары, җирле үзидарә органнары тарафыннан юл хәрәкәтен оештыру өлкәсендәге вәкаләтләрне тормышка ашыруга дәүләт контроле (күзәтчелеге) (03.03.06 *).»;

3.3 пунктта:

туксан дүртенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«законнар белән билгеләнгән тәртиптә җиңел такси белән пассажирлар йөртү һәм багаж ташу өлкәсендә төбәк дәүләт контролен (күзәтчелеген) гамәлгә ашыра;»;

йөз дүртенче абзац үз көчен югалткан дип танырга;

йөз уникенче һәм йөз унөченче абзацларны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«законнар белән билгеләнгән тәртиптә Татарстан Республикасы башкарма хакимият органнары, җирле үзидарә органнары тарафыннан юл хәрәкәтен оештыру өлкәсендәге вәкаләтләрне тормышка ашыруга дәүләт контролен (күзәтчелеген) гамәлгә ашыра;

законнар белән билгеләнгән тәртиптә автомобиль транспортында, шәһәр җир өсте электр транспортында һәм юл хуҗалыгында төбәк дәүләт контролен (күзәтчелеген) гамәлгә ашыра.».

2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы территориясендә юл хәрәкәтен оештыру өлкәсендә республика дәүләт контролен гамәлгә ашыру тәртибен раслау турында» 2019 ел, 30 март, 246 нчы карары үз көчен югалткан дип танырга.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин